**СОВЕТ УСАДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Усады, ул. Советская,41

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСАД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Усад авылы, Совет ур, 41

Тел./факс: +7(84365) 73-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**28 март 2019 ел** **№168**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Усад авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2014 елның 07 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, , «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Усад авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районының 2018 елның 10 маендагы 130 номерлы Усад авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Усад авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә (2018 елның 24 сентябрендәге 144 номерлы Советы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.6. Этне урамда йөртү, өч айга кадәрге көчекләрне һәм махсус сумкага (контейнерга) яки аларны йөртүче кеше кулына кечкенә этләрне урамда йөртү очракларыннан тыш, сылтау (этне тотып торучы башка җайланма), муенчак һәм борынчак куллану белән башкарылырга тиеш. 2014 елның 07 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән этнең муенчагында аның идентификация номеры күрсәтелергә тиеш. Этне тезгеннән башка урамда йөртү торак пунктлар чикләреннән читтә, шулай ук мондый выгулны рөхсәт итә торган билгеләр урнаштырылган урыннарда рөхсәт ителә.".

2. Әлеге карар Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтта http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш һәм рәсми халыкка җиткергәннән соң үз көченә керә.

Совет председателе,
Усад авыл җирлеге башлыгы О.А.Фомин